**ГЛАВА СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**19 октябрь 2022 ел** **№8**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

2022 елның 29 октябрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Ташсу ав., Гагарина ур., 10 йорт янында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

Ташсу торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Урам утларын ремонтлауга;
- Күмү урыннарын тотуга;
- МТЗ-82 тракторына элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга;
- Трактор тотуга (ГСМ, запас частьләр, хезмәт хакы);

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Суыксу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев